КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 6 июль г.Казань № 461

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 – 2016 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 785 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 – 2016 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 785 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче, 2015 ел, 22 август, 615 нче, 2016 ел, 22 декабрь, 975 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 – 2016 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – дәүләт программасы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә «2014 – 2016» саннарын «2014 – 2019» саннарына алмаштырырга;

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 ел, 20 август, 718 нче карары белән расланган «Россия милләтенең берлеген ныгыту һәм Россия халыклары этномәдәниятен үстерү (2014 – 2020 еллар)» федераль максатчан программасы белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел, 29 декабрь, 1532 нче карары белән расланган «Дәүләт илкүләм сәясәтен тормышка ашыру» Россия Федерациясе дәүләт программасы белән» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2014 – 2016» саннарын «2014 – 2019» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 – 2016 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин